**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Салтык авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**29 апрель 2021 ел** **№18**

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының " Олы Салтык авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Советы, Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 12.03.20021 ел, № 02-06-2021/9 протестын карап, **карар** кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләре»нә 14.06.2017 ел, 38 тамга белән кабул ителгән карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. I бүлектәге 6 пунктның 28 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-калдыкларны саклау һәм күмүне үз эченә алган калдыкларны урнаштыру, үз чиратында калдыкларны саклау, утильләштерү, йогышсызландыру, күмү максатларында, унбер айдан артык вакыт эчендә махсус объектларда калдыклар туплау буларак билгеләнде.»

2. III бүлектэге 19 нчы пунктның 3нче пунктчасын төшереп калдырырга;

3. III бүлектэге 19 нчы пунктның 4 нче пунктчасын төшереп калдырырга;

4. III бүлекнең 39.4нче пунктындагы «йорт чикләрендә яшел үсентеләрне тәртиптә тоту, куаклар һәм агачларны санитар кисүне үткәрү» сүзен тошереп калдырырга;

5. III бүлекнең 39.5нче пунктын төшереп калдырырга;

6. III бүлекнең 39.9нчы пунктын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов урамы, 126 йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Мәрәтхуҗа авылы, Ленин урамы, 61йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Даныш авылы, Кооператив урамы, 71 йорт, һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан

Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми халыкка хәбәр ителгән (бастырып чыгарылган) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Салтык авыл җирлеге башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Салтык авыл җирлеге Советы Рәисе Р.М. Вафин**